ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.09.2019 г. Заинск № 477

**«2020 – 2022 елларда Зәй муниципаль районында күпкатлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү региональ программасы кыска сроклы планын гамәлгә ашыруны раслау турында”**

“Торак-коммуналь хуҗалыкны формалаштыруга булышлык фонды турында” (21.07.2007 ел) 185нче федераль законын, “Татарстан Республикасында торак- коммуналь хуҗалыкны формалаштыруга булышлык фонды турында” (14.11.2007 ел) Татарстан Республикасы Президентының 611нче Указын, “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрүне оештыру турында” (25.06.2013) 52нче Татарстан Республикасы законын үтәү йөзеннән һәм гражданнар яшәеше өчен куркынычсыз, имин шартлар тудыру максатында, Татарстан Республикасы Зәй мунииипаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2020 – 2022 елларда муниципаль районда күпкатлы йортлардагы гомуми милекне капиталь ремонтлау региональ программасының кыска сроклы планын, кушымтага нигезләнеп, раслау.

2. Башкарма комитетның оештыру бүлегенә элеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга.

3. Карарның үтәлешенә күзәтчелек итүне Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Н.А.Нифатовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Хафизов**

Зәй муниципаль районы башкарма
комитетының 09.09.2019 ел
477 карары белән
РАСЛАНГАН.

# Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпкатлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү региональ программасын гамәлгә ашыруда 2020 - 2022 елларга исәпләнгән кыска сроклы план

## I. Гомуми кагыйдәләр (положения)

Әлеге 2020 – 2022 елларга исәпләнгән Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпкатлы йортлардагы гомуми милекне капитал төзекләндерү региональ программасы кыска сроклы планы (алга таба – кыска сроклы план, Региональ программа) Россия Федерациясе Торак кодексы, “Торак-коммуналь хужалыкны формалаштыруга булышлык фонды турында” (21.07.2007 ел) 185нче федераль закон (алга таба – федераль закон), “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү үткәрү” (25.06.2013 ел) 52нче Татарстан Республикасы законына (алга таба - Татарстан Республикасы законы) нигезләнеп, программаны гамәлгә ашыру, күпкатлы йортларда капиталь төзекләндерү эшләренең вакытын аныклаштыру, планлаштырылган хезмәт күрсәтү төрләрен һәм эшләрен ачыклау, дәүләт һәм муниципаль ярдәм күләмнәрен һәм төрләрен билгеләү максатында эшләнә.

## II. Кыска сроклы планның төп максаты һәм бурычлары

Кыска сроклы планның төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

муниипаль районда торак фондны саклау, яңадан торгызу һәм аның сыйфатын күтәрү;

гражданнарның яшәеше өчен куркынычсыз һәм уңайлы шартлар тудыру;

күпкатлы йортлардагы гомуми милеккә капиталь төзекләндерү үткәрүдә дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм күрсәтү.

Кыска сроклы планның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Халык белән актив үгетләү-аңлату эшләре алып бару;

Кыска сроклы планны тормышка ашыру эшен башкаручыларны сайлаганда процедураларның үтәкүренмәлелеген һәм ачыклыгын тәэмин итү;

Озакка чыдый торган материаллар һәм ресурсларны саклау технологияләре кулланып капиталь төзекләндерү үткәргәндә нәтиҗәле техник карарлар кабул итү һәм комплекслылыктан файдалану.

Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру вакыты – 2020-2022 еллар.

Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру 394088,15 мең квадрат метр мәйдан биләп торган 133 фатирда яшәүче 18763 гражданның куркынычсыз һәм унайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Әлеге кыска сроклы планны үтәү буенча планлаштырылган күрсәткечләр 1 нче кушымтада бирелә.

## III. Күпфатирлы йортларда капиталь төзекләндерү күләмнәре

| Күпфатирлы йортларда 2020 елда үткәреләчәк төзекләндерү эшләре һәм хезмәт күрсәтүләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эш күләме | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2020 | 2021 | 2022 |
| 1.Түбәне төзекләндерү, шул исәптән җиллләтелми торганнарын җилләтелерлек итеп үзгәртү, түбәгә чыгу урыннарын көйләү | кв.метр | 4 243,50 | 2 670,00 | 5 447,19 |
| 2. Йорт эчендәге инженерлык системалары - электр, газ, су белән тәэмин итү, юынтык сулар чыгу торбаларын төзекләндерү, алыштыру, шул исәптән йорт эчендәге җылыту элементларын, механик, электр санитар-техник җиһазларны төзекләндерү, алыштыру, шул исәптән: | мең метр | 6361,66 | 1025,00 | 13711,45 |
| 2.1 электр белән тәэмин итү | кв.метр | 1223,68 | 1025 | 1622,49 |
| 2.2 җылылык белән тәэмин итү | метр оз. | 1151,56 | 0 | 4149,33 |
| 2.3 су белән тәэмин итү | метр оз. | 2813,13 | 0 | 6211,66 |
| 2.4 юынтык сулар чыгу | метр оз. | 1173,29 | 0 | 1727,97 |
| 3.Ресурслардан (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын сулар, электр энергиясе, газ) файдалануны исәпкә алучы гомумйорт приборлары кую | данә | 0 | 0 | 0 |
| 4. Ресурслардан файдалануны көйләү, алар белән идарә итү чатлыклары кую | данә | 0 | 0 | 0 |
| 5. Яраксыз хәлгә килгән лифт җиһазларын алыштыру | данә | 8 | 4 | 0 |
| 6. Лифт шахталарын төзекләндерү | данә | 0 | 0 | 0 |
| 7. Гомуми милеккә керүче подвал биналарын төзекләндерү | мең кв.метр | 0 | 0 | 0 |
| 8. Фасадны төзекләндерү | кв.метр | 6336,2 | 9114,5 | 11882,23 |
| 9. Фасадны җылыту | мең кв.метр | 0 | 0 | 0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10.Йорт фундаментын төзекләндерү | мең .куб. метр | 0 | 0 | 0 |
| 11.Йортка энергетик актан карау үткәрү | данә | 0 | 0 | 0 |
| 12.Йортларда техник инвентарьлаштыру эшен үткәрү, техник паспортлар ясау | данә | 53 | 68 | 12 |
| 13. Йорт подъездларын төзекләндерү | мең кв.метр | 644,5 | 0 | 374,5 |
| 14.Йортларның янгын кисәтүе системаларын төзекләндерү | мең кв.метр | 0 | 0 | 0 |
| 15.Төзелешкә контрольне гамәлгә ашыру | данә | 53 | 68 | 12 |
| 16.Проект документларына дәүләт экспертизасы эшләп, аны үткәрү | данә | 53 | 68 | 12 |
| 17.Күпкатлы йортларның гомуми милке составына кермәгән өлешләрне, технологик һәм конструктив үзенчәлекләр нәтиҗәсендә сүтелгән яки җимерелгән төзекләндерердәй (алыштырырдай) корылма һәм инженерлык системаларын яңадан торгызу, шулай ук төзекләндерү эшләре төгәлләнгәннән соң уңайлыклар тудыру | данә | 0 | 0 | 0 |
| 18. Көйләү, алмаштыру ИТП | | 46 | 64 | 0 |

Күпкатлы йортларда капиталь төзекләндерү күләмнәре әлеге Кыска сроклы планның 2нче кушымтасында бирелә.

## IV. Капиталь төзекләндерү үткәрүне өлешчә финанслау күләмнәрен нигезләү

Планга кертелгән йортларны капиталь төзекләндерүне өлешчә финанслау күләмнәрен нигезләү расчеты федераль законның 3нче өлеше, 18нче матдәсенә нигезләнә.

Өлешчә финанслауның минималь күләме Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлардан федераль законның 18нче матдәсендә күрсәтелә һәм ул 48,3 процентны тәшкил итә

## V. Ресурс белән тәэмин итү

Кыска сроклы планны финанслау чыганаклары булып Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет һәм күпкатлы йорттагы торак милекчеләре средстволары тора.

Финанслауның гомуми күләме, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджетыннан – 51,4 млн. сум;

муниципаль район бюджетыннан - 49,7 млн. сум;

йортлардагы торак милекчеләреннән – 109,1 млн. сум.

Капиталь төзекләндерү үткәрүгә финанс средстволары күләме

| № п/п | Күпфатирлы йортларда 2020 елда үткәреләчәк төзекләндерү эшләре һәм хезмәт күрсәтүләр исемлеге | Сумма, 2020 елга млн. сум | Сумма, 2021елга млн. сум | Сумма, 2022 елга млн. сум |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Түбәне төзекләндерү, шул исәптән җилләтелми торганнарын җилләтелерлек итеп үзгәртү, түбәгә чыгу урыннарын көйләү | 9,35 | 7,92 | 14,4 |
| 2. | Йорт эчендәге инженерлык системалары - электр, газ, су белән тәэмин итү, юынтык сулар чыгу торбаларын төзекләндерү, алыштыру, шул исәптән йорт эчендәге җылыту элементларын, механик, электр санитар-техник җиһазларны төзекләндерү, алыштыру, шул исәптән: | 17,02 | 2,01 | 30,5 |
| 2.1 | электр белән тәэмин итү | 3,79 | 2,01 | 3,4 |
| 2.2 | җылылык белән тәэмин итү | 4,7 | 0 | 9,3 |
| 2.3 | су белән тәэмин итү | 6,5 | 0 | 13,0 |
| 2.4 | юынтык сулар чыгу | 2,03 | 0 | 4,8 |
| 3. | ИТП көйләү һәм алыштыру | 27 | 36,81 | 0 |
| 4. | Ресурслардан (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын сулар, электр энергиясе, газ) файдалануны исәпкә алучы гомумйорт приборлары кую | 0 | 0 | 0 |
| 4. | Ресурслардан файдалануны көйләү, алар белән идарә итү чатлыклары кую | 0 | 0 | 0 |
| 5. | Яраксыз хәлгә килгән лифт җиһазларын алыштыру | 7,22 | 3,86 | 0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 6. | Лифт шахталарын төзекләндерү | 0 | 0 | 0 |
| 7. | Гомуми милеккә керүче подвал биналарын төзекләндерү | 0 | 0 | 0 |
| 8. | Фасадны төзекләндерү | 7,64 | 10,7 | 13,6 |
| 9. | Фасадны җылыту | 0 | 0 | 0 |
| 10. | Йортның фундаментын төзекләндерү | 0 | 0 | 0 |
| 11. | Йортка энергетик актан карау үткәрү | 0 | 0 | 0 |
| 12. | Йортларда техник инвентарьлаштыру эшен үткәрү, техник паспортлар ясау | 0,4 | 0,47 | 0,8 |
| 13. | Подъездларны төзекләндерү | 4,5 | 0 | 4,7 |
| 14. | Йортларның янгын кисәтүе системаларын төзекләндерү | 0 | 0 | 0 |
| 15. | Проект документларына дәүләт экспертизасы эшләп, аны үткәрү | 3,6 | 3,9 | 1,8 |
| 16. | Проект документларына дәүләт экспертизасы эшләп, аны үткәрү | 0 | 0 | 0 |
| 17. | Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | 1,08 | 0,92 | 0,8 |
| 18. | Күпкатлы йортларның гомуми милке составына кермәгән өлешләрне, технологик һәм конструктив үзенчәлекләр нәтиҗәсендә сүтелгән яки җимерелгән төзекләндерердәй (алыштырырдай) корылма һәм инженерлык системаларын яңадан торгызу, шулай ук төзекләндерү эшләре тәгәлләнгәннән соң уңайлыклар тудыру | 0 | 0 | 0 |
| 19. | Ресурслардан куллануны көйләүче исәпләү чатлыклары урнаштыру(ТМШ, ТК, ТТК яки башка кулланучылар кооперативлары яисә йортта яшәүчеләр исәбенә генә, өстәвенә 2014 -2019 елларда чатлыкларны урнаштыру кыска сроклы план нигезендә һәм төзелгән килешүләр буенча финанслана) | 0 | 0 | 0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 20. | 2017 елның 1 июненә кадәр куелган (ТМШ, ТК, ТТК яки башка кулланучылар кооперативлары яисә йортта яшәүчеләр хисабына куелган) йорт коммуналь ресурслары чыгымнарын гомуми исәпләү приборларын алыштыру, кую | 0 | 0 | 0 |
| 21. | Җылләтү шахталарын төзекләндерү | 0,2 | 0 | 0 |
| | Барлыгы: | **78,01** | **66,59** | **66,60** |

Купфатирлы йортлар исемлеге, капиталь төзекләндерү үткәрү бәясе күрсәтелеп, шул исәптән Фонд средстволары хисабына, элеге Кыска сроклы планның 3нче кушымтасында бирелә.

## V. Хезмәт күрсәтү һәм капиталь төзекләндерү эшләренең чик бәясе.

Хезмәт күрсәтү һәм капиталь төзекләндерү эшләренең чик бәясе 2020 -2022 елларга гомуми мәйданның 1 квадрат метрына 14 мең сум тәшкил итә.

Хезмәт күрсәтү һәм капиталь төзекләндерү эшләренең чик бәясеннән чыкканда, шулай ук Кыска сроклы планда каралмаган хезмәт күрсәтүләр, эшләр башкарылганда, фатир хуҗалары (милекчеләр) хисабына (капиталь төзекләндерүгә өстәмә взнос формасында) башкарыла.

## VI.Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру механизмы

**ТР Зәй муниципаль районы башкарма комитеты:**

министрлыкка өч елга, күрсәтелгән вакыт чикләрендә елларга бүлеп, Региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын төзеп тапшыра;

министрлыкка муниципаль берәмлек тарафыннан финанс ярдәме күрсәтү шартларын раслаучы норматив-хокук актлары һәм башка документларның күчермәсен тапшыра;

торак законы нигезендә, кыска сроклы планда билгеләнгәнчә капиталь төзекләндерү эшләрен үткәрүгә җирле бюджеттан финанс ярдәме суммасын күчерә;

Региональ оператор белән килешү нигезендә капиталь төзеекләндерү эшләрендә техник заказчы функциясен үти;

башкарылган эшләр актын, эшне кабул итү актларын (расланган сметада каралмаганны, шулай ук чыгымнар артып китүне исәпкә алмыйча) килештерә;

капиталь төзекләндерүгә бүленгән средстволарның максатчан тотылуын контрольдә тота;

муницaverage берәмлек буенча Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру максатында мәгълүмат базасы булдырып (йорттагы кеше яши һәм яшәми

торган мәйданнар турында мәгълүматларны кертеп), аны һәрвакыт яңартып тора;

Министрлыкка, Кыска сроклы план буенча эш башкаручыларга торак-коммуналь хужалыкны формалаштыруга булышлык фонды – дәүләт корпорациясенә отчетлар өчен документлар һәм мәгълүмат бирә.

**ТМШ, ТТК, ТК, ИО:**

башкарылган эш күләме буенча тикшерү актларын, дефект ведомостьларын килештерәләр;

Региональ оператор белән килешүләр төзиләр (алар нигезендә ТМШ, ТТК, ТК, ИО торак милекчеләренең региональ оператор счетына бара торган төзекләндерүгә взнослары түләнүен, аларның ай саен күчерелүен, шулай ук бурычлар һәм пениларны эзләп алуны тәэмин итәләр);

проект документларын килештерүне тәэмин итәләр;

бина милекчеләренә төзекләндерү эшләре башлауның вакыты турында, хезмәт күрсәтү һәм эш күләмнәре, аларның бәяләре, финанслау чыганаклары, тәртибе һәм төзекләндерү эшләре белән бәйле башка тәкъдимнәрне җиткерәләр;

йортта яшәүче милек хуҗалары белән капиталь төзекләндерү мәсьәләләре буенча җыелышлар үткәрәләр;

капиталь ремонт объектларына керүне тәэмин итәләр;

эшнең үзвакытында һәм сыйфатлы итеп башкарылуын контрольдә тоталар, шулай ук эш тәмамланганнан соң, актларга кул кую хокукы белән, объектны кабул итеп алуда катнашалар;

капиталь ремонт буенча йортны, инженерлык системаларын аварияләрсез файдалануда билгеләнгән гарантия срогыннан да ким булмаган вакытны тәэмин итүне үз эченә алган дефект ведомостьларын, проект-смета һәм башкарма документларны саклыйлар.

Торак милекчеләре:

тикшерү актларын, дефект ведомостьларын үзара килештерәләр;

йортларда капиталь төзекләндерүне үзвакытында һәм сыйфатлы итеп башкаруны контрольдә тоталар, шулай ук эш тәмамланганнан соң, актларга кул кую хокукы белән, объектны кабул итеп алуда катнашалар.

Подрядчы оешмалар:

эшне Кыска сроклы планда билгеләнгән һәм подряд килешүендә күрсәтелгән вакытта башкаруны тәэмин итә;

башкарылган эшләр актларын КС-2, КС-3 формалары буенча төзи;

эшләрне башкарганда төзелеш контролен тәэмин итә;

эшләрне узвакытында һәм сыйфатлы итеп башкаруда җаваплылык тота;

объектны файдалануга тапшыруны тәэмин итә;

подряд килешүендә каралган башка эшләрне башкара.

**Техник заказчылар:**

проект документларын, шул исәптән сметаны әзерли һәм раслата;

капиталь төзекләндерү барышында төзелеш контролен үти;

башкарылган эшләрне кабул итеп алганда катнаша, башкарылган эшләр актын яраклаштыра;

объектны кабул итеп алганда катнаша, эшне кабул итү буенча комиссия төзи, эшне кабул иткәндә комиссия актларын тәңгәлләштерә;

капиталь төзекләндерү буенча эшләрнең вакытында һәм сыйфатлы итеп башкарылуында җаваплылык тота;

проект ясау оешмасыннан проект документларын кабул итә;

күрсәтелгән хезмәтләр һәм башкарылган эшләрне кабул итү турында актка кул куелганнан соң 10 көн эчендә тапшырылган йорт белән идарә итүче затка үткәрелгән төзекләндерү эшләре турында (шул исәптән проект-смета документлары, хезмәт күрсәтү килешүе күчермәләре), финанс документларыннан тыш, капиталь төзекләндерү белән бәйле документларны тапшыра;

техник заказчыга закон нигезендә каралган башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

Кыска сроклы планны планлаштыру, үтәү һәм мониторингны “Торак фонды мониторингы” бердәм мәгълүмат продукты гамәлгә ашыра.

## VII. Подрядчы оешмаларны сайлау.

Хезмәтләр күрсәтү һәм күпфатирлы йортлар гомуми милкен капиталь төзекләндерү өчен подрядчы оешмаларны сайлау Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 615нче карары белән расланган Положениедә билгеләнгән тәртиптә Региональ оператор тарафыннан башкарыла.

Зәй муниципаль районы территориясендә
урнашкан күпфатирлы йортларның гомуми
милкен капиталь төзекләндерү буенча 2020 -2022
елларга исәпләнгән кыска сроклы планына 3нче
кушымта

# Планлаштырылган күрсәткәчләр

**Региональ программаның 2020 -2022 елларга исәпләнгән кыска сроклы планын үтәү**

| Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү региональ программасын үтәү күрсәткечләре (алга таба - региональ программа) | Үлчәү берәмлеге | 2020 елга план | 2021 елга план | 2022 елга план |
|---|---|---|---|---|
| 1. Капиталь төзекләндерү үткәрелгән күпфатирлы торак фонды( МКД - КФЙ) : | | | | |
| күпфатирлы йортлар саны | берәмлек | 53 | 68 | 12 |
| торак фондның гомуми мәйданы, барлыгы | млн.кв.метр | 0,17 | 0,18 | 0,47 |
| шул исәптән гражданнарның шәхси милкендә булган торак биналарның гомуми мәйданы | млн.кв.метр | 0,16 | 0,15 | 0,04 |
| 2. Региональ программага кертелгән КФЙ (МКД) гомуми санына карата капиталь төзекләндерү үткәрелгән йортларның өлеше | процент | 100 | 100 | 100 |
| 3. Регионал программага кертелгән КФЙ гомуми санына карата, ресурсларны исәпкә алу һәм бүлү чатлыклары куелган КФЙ өлеше : | | | | |
| жылылык энергиясе | процент | 100 | 100 | 100 |
| кайнар су | процент | 100 | 100 | 100 |
| салкын су | процент | 100 | 100 | 100 |
| электр энергиясе | процент | 100 | 100 | 100 |
| 4. Үткәрелгән капиталь төзекләндерүне финанслау күләме, барлыгы, шул исәптән: | млн.сум | 78,20 | 66,50 | 66,50 |
| Татарстан Республикасы һәм җирле бюджетлар хисабына | млн.сум | 23,50 | 15,20 | 17,30 |
| торак милекчеләре ширкәтләре, ТТК һәм башка махсуслашкан кулланучылар кооперативлары яки бина милекчеләре хисабына | млн.сум | 39,60 | 35,50 | 33,29 |

*МКД - многоквартирный дом

Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан
күпфатирлы йортларның гомуми милкен капиталь
төзекләндерү буенча 2020 -2022 елларга исәпләнгән
кыска сроклы планына 1нче кушымта

## Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларның гомуми милкен капиталь төзекләндерү буенча 2020 -2022 елларга исәпләнгән кыска сроклы планын үтүнең планлаштырылган күрсәткечләре

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең исеме | Гомуми мәйдан, кв.метрларда | Региональ программа расланган датага йортта теркәлгән яшәүчеләр саны | Күпфатирлы йортлар саны | | | | | Капиталь төзекләндерү бәясе | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | барлыгы | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | барлыгы |
| | **2020 ел.** | | | | | | | | | | | | |
| | Зәй муниципаль районы буенча барлыгы | 170 596,13 | 7933 | | | | 53 | 53 | | | | 78 019 750,20 | 78 019 750,20 |
| 1 | Зәй муниципаль районы | 170 596,13 | 7933 | | | | 53 | 53 | | | | 78 019 750,20 | 78 019 750,20 |
| | **2021 ел** | | | | | | | | | | | | |
| | Зәй муниципаль районы буенча барлыгы | 176 103,59 | 8526 | | | | 68 | 68 | | | | 66 595 412,81 | 66 595 412,81 |
| 1 | Зәй муниципаль районы | 176 103,59 | 8526 | | | | 68 | 68 | | | | 66 595 412,81 | 66 595 412,81 |
| | **2022 ел** | | | | | | | | | | | | |
| | Зәй муниципаль районы буенча барлыгы | 47 388,43 | 2304 | | | | 12 | 12 | | | | 66 593 683,81 | 66 593 683,81 |
| 1 | Зәй муниципаль районы | 47 388,43 | 2304 | | | | 12 | 12 | | | | 66 593 683,81 | 66 593 683,81 |

*МКД - многоквартирный дом

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2022 ел | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Муниципаль район буенча барлыгы | | 66593683,81 | 30 110 998,09 | | | 5 447,19 | 14 420 000,00 | | | 11 882,23 | 13 650 000,00 | | | | | | | 374,50 | 4 735 408,43 | | | | |
| 1 | Зәй ш., Төзүчеләр ур., 4 | 8 588 728,00 | 4 260 000,00 | | | 961,50 | 2 300 000,00 | | | 1 749,00 | 1 600 000,00 | | | | | | | | | | | | |
| 2 | Зәй ш., Ленин ур., 23 | 2 266 998,00 | | | | 698,00 | 2 110 000,00 | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3 | Зәй ш., Җиңү пр-кты, 1/07 | 3 241 390,00 | 2 890 998,09 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4 | Зәй ш., Октябрь ур., 7 | 2 637 390,00 | | | | 1 296,10 | 2 450 000,00 | | | 1 922,00 | 2 100 000,00 | | | | | | | | | | | | |
| 5 | Зәй ш., Рафиков ур., 8 | 4 059 370,00 | | | | 502,73 | 1 750 000,00 | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6 | Зәй ш., Төзүчеләр ур., 8 | 2 361 818,00 | | | | 951,80 | 2 200 000,00 | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7 | Зәй ш., Җиңү пр-кты, 1/18 | 8 656 974,00 | 8 150 000,00 | | | | | | | 3 080,00 | 750 000,00 | | | | | | | 374,50 | 4 735 408,43 | | | | |
| 8 | Зәй ш., Ленин ур., 19 | 13 817 027,81 | 5 840 000,00 | | | 534,33 | 1 860 000,00 | | | 2 462,40 | 3 100 000,00 | | | | | | | | | | | | |
| 9 | Зәй ш., Казан ур., 10 | 9 125 704,00 | 5 580 000,00 | | | | | | | 1 906,00 | 2 100 000,00 | | | | | | | | | | | | |
| 10 | Зәй ш., Ленин ур., 1 | 7 611 300,00 | 3 390 000,00 | | | 502,73 | 1 750 000,00 | | | 490,00 | 2 000 000,00 | | | | | | | | | | | | |
| 11 | Зәй ш., Яшьлек ур., 3 | 2 116 656,00 | | | | | | | | 272,83 | 2 000 000,00 | | | | | | | | | | | | |
| 12 | Зәй ш., Клуб ур. 20 | 2 110 328,00 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |